| | | |
|---|---|---|
| Республика Татарстан<br>Исполнительный комитет Менделеевского муниципального района | | Татарстан Республикасы<br>Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

__16.03.2020_________ Менделеевск ш. № ____187 _____

2020 елга граждан кеременең
һәм салым салынырга тиешле
мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен
раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясы, 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы «социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» һәм Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 18 сентябрендәге 553/пр номерлы боерыгы белән «2019 елның IV кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында», Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен чик күрсәткечләр билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы чиге:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 1 749742сум;

1.1.2. ике кешелек гаилә өчен – 2227008 сум;

1.1.3. өч кешелек гаилә өчен – 2863296 сум;

1.1.4. дүрт кешелек гаилә өчен – 3817728 сум;

1.1.5. биш кешелек гаилә өчен – 4772160 сум;

1.1.6. алты кешелек гаилә өчен – 5726592 сум;

1.1.7. җиде кешелек гаилә өчен – 6681024сум;

1.2. гражданның һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 17413,77 сум
1.2.2. ике кешелек гаилә өчен – 11081,50 сум
1.2.3. өч кеше һәм аннан да күбрәк булган гаилә өчен – 9498,42 сум.

2. Торак сәясәте бүлегенә, шәһәр хуҗалыгына һәм Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының сәүдә бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 бүлекләрендә күрсәтелгән иң чик күрсәткечләрен торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда кулланырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.А.Абдуллин

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ:

Башкарма комитетның
юридик бүлеге начальнигы Е.С.Царева

1 нче кушымта

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү методикасы (2019 елга)**

1. Базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече

СЖ= НП*РС* РЦ, кайда

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны сатып алу бәясенең исәп-хисап күрсәткече яисә базар хакының иң чик күрсәткече;

НП - гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС-гаилә әгъзалары саны;

РЦ - бер квадрат метр мәйданның уртача исәпләнгән базар бәясе, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 18.09.2009 ел, №553/пр боерыгы.

а) ялгыз яшәүче гражданин өчен: СЖ=53024*33= 1749792сум

б) ике кешелек гаиләгә: СЖ=53024*42=2227008сум

в) өч кешелек гаиләгә: СЖ=53024* 18*3=2863296сум

г) дүрт кешелек гаиләгә: СЖ=53024* 18*4=3817728сум

д) биш кешелек гаиләгә: СЖ=53024* 18*5=4772160сум

ж) алты кешелек гаиләгә: СЖ=53024*18*6=5726592сум

з) җиде кешелек гаиләгә: СЖ=53024*18*7=6681024сум

2. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең икеле әһәмияте - ПД=0,7*СЖ*ПС/ (1-[(1+ПС) - КП]}/ (0,25*РС), кайда

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече;

ПС - кредит буенча процент ставкасы (10,2/12);

КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (240 ай);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасының һәм фатир бәясенең нисбәте;

0,25 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кереме белән нисбәте;

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

ПД=(0,7*1749792*0,85) / (1-[(1+0,85) - 240]}/ (0,25*1)= 17413,77

б) ике кешелек гаиләгә:

ПД=(0,7*2227008 *0,85) / (1-[(1+0,85) - 240]}/ (0,25*2)= 11081,50

в) өч кеше һәм аннан да күбрәк булган гаилә өчен:

ПД=(0,7* 2863296 *0,85)/ (1-[(1+0,85) - 240]}/ (0,25*3)= 9498,42